РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.05.2021 № 545-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Башкарма комитетының резерв
фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы
Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә, җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен планлаштырылган күләмдә гамәлгә ашыру өчен финанс мөмкинлекләрен тәэмин итү максатларында, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау буенча комиссия төзергә.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау буенча комиссия составын расларга (кушымта итеп бирелә).

4. Түбәндәге карарларны үз көчен югалткан дип танырга:

– “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты резерв фондының акчаларын тоту тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2006 елның 30 декабрендәге 728-п номерлы карары;

– “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 2013 елның 28 июнендәге 877-п номерлы карары.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 19 маендагы
545-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы Нигезләмә**

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының (алга таба - башкарма комитет) резерв фонды, Саба муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына каралмаган, көтелмәгән чыгымнарны һәм район әһәмиятендәге чараларны финанслау өчен төзелә.

**2.** Башкарма комитетның резерв фонды күләме тиешле финанс елына Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карар белән билгеләнә һәм бюджет чыгымнарының гомуми күләменең тиешле чорга бюджет турындагы карарда расланган 3 проценттан арта алмый.

**3.** Башкарма комитетның резерв фонды акчалары түбәндәгеләрне финанслауга тотыла:

– агымдагы финанс елында урыны булган табигый бәла-казаларның һәм башка гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү буенча авария-торгызу эшләре уздыру;

– гражданнар оборонасы, табигатьне саклау, эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;

– бер тапкыр бирелә торган премияләр түләү һәм гражданнарга дәвалануга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү, янгыннарның нәтиҗәләрен һәм техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү;

– иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә, иҗат коллективларына һәм үзешчән сәнгать коллективларына матди ярдәм күрсәтү;

– җирле әһәмияттәге проблемалар буенча очрашулар, симпозиумнар, күргәзмәләр һәм семинарлар уздыру;

– җирле әһәмияттәге смотрлар, конкурслар һәм башка чаралар уздыру;

– китаплар бастыру, язучылар, шагыйрьләр, рәссамнар, композиторларның әдәби әсәрләрен сатып алу;

– музей фондлары булдыру;

– социаль-мәдәни өлкәне, физик культураны һәм спортны үстерүгә ярдәм итү;

– район һәм җирле әһәмияттәге оешмалар һәм учреждениеләр гаризалары буенча ремонт һәм торгызу эшләре башкару;

– Саба муниципаль районы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә финанс ярдәме чаралары уздыру;

– Саба муниципаль районы ихтыяҗлары өчен югары уку йортларының максатчан программасы буенча студентларны укыту;

– иҗтимагый оешмаларга өлешчә финанс ярдәме;

– агымдагы финанс елына Саба муниципаль районы бюджетында акчалар каралмаган һәм киләсе финанс елына бюджет расланганчы кичектерелә алмаган Район башкарма комитеты карары буенча үткәрелә торган җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә караган чаралар һәм карарлар уздыру;

– Район Советы һәм Район Башкарма комитеты карары буенча үткәрелә торган башка чаралар.

**4.** Резерв фондыннан акча алуга дәгъва итүчеләр Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән максатларга, проектларны һәм смета-финанс исәп-хисапларын да кертеп, чыгымнарның кирәклеген, кичектергесез булуын һәм алдан көтелмәгән булуын раслаучы, шулай ук кызыксынган органнар төзү зарурилыгы турында документлар тапшырыла.

**5.** Саба муниципаль районы Башкарма комитеты 3 (өч) көн эчендә Башкарма комитетның резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турында кергән мөрәҗәгатьләрне һәм чыгымнарны кичектереп булмауны һәм аларны булдырмау кирәклеген раслый торган документларны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан (алга таба - Комиссия) акчалар бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау комиссиясенә түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрә:

– резерв фондыннан акча бүлеп бирү зарурлыгы яки зарурлыгы булмау турында;

– бүлеп бирелә торган акчаларның күләмен билгеләү турында.

**6.** Комиссия составы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

**7.** Комиссия утырышы Саба муниципаль районы Башкарма комитетыннан мөрәҗәгатьләр һәм документлар кергән саен уздырыла.

Комиссия рәисе комиссияне җитәкли һәм аның эшен оештыра.

Комиссия утырышы составының кимендә өчтән икесе булганда тулы хокуклы.

Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Комиссия карарлары анда катнашучыларның гомуми санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора. Утырыш беркетмәсенә һәм карар кабул итүгә комиссия рәисе имза сала.

Комиссия әгъзасы утырышта катнашмаган очракта, ул карала торган мәсьәләләр буенча язма рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы, аның фикере утырышта игълан ителә һәм беркетмәгә кушып бирелә.

Комиссия әгъзасы кабул ителгән карар белән килешмәгәндә, язма рәвештә үзенең аерым фикерен бәян итәргә хокуклы, ул утырыш беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушып бирелергә тиеш.

**8.** Комиссия карары тәкъдим итү характерына ия. Комиссиянең кабул ителгән карары 2 (ике) көн эчендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

**9.** Район Башкарма комитетының резерв фонды акчалары Саба муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе нигезендә бирелә. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының район Резерв фондыннан акчалар

бүлеп бирү турындагы күрсәтмәсе, югарыда санап үтелгән чараларны гамәлгә ашыручы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм оешмалары карамагындагы акчалар җитәрлек булмаган яисә булмаган очракта, басылып чыга.

**10.** Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карамагында резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турында ассигнованиеләрнең гомуми күләме һәм аларны алучыларга һәм уздырыла торган чараларга бүлү күрсәтелә.

**11.** Башкарма комитетның резерв фондыннан бүлеп бирү турында Саба муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәләре проектлары, бүлеп бирелгән акчаларның күләмен күрсәтеп һәм аларны тоту юнәлешләрен күрсәтеп, Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе кушуы буенча әзерли.

**12.** Резерв фондыннан акчалар түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә. Резерв фондыннан акчалар максатчан характерга ия һәм башка максатларда кулланыла алмый.

**13.** Җирле үзидарә органнары, резерв фонд акчалары бүленә торган физик һәм юридик затлар, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә акчалардан максатчан файдаланмаган өчен җаваплы булалар һәм тиешле чаралар уздырганнан соң бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына, раслаучы документлар белән 1 нче кушымта нигезендә, башкарма комитетның резерв фондыннан бирелгән акчаларның максатчан кулланылуы турында хисап тапшыралар

**14.** Бүлеп бирелгән акча үзләштерелмәгән, бирелгән акчаларны максатчан кулланмаган, дөрес булмаган белешмәләр булган документларны тапшырган очракта, акчалар Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

**15.** Акча бирүне туктату һәм (яисә) кире кайтару турындагы карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты кабул итә.

**16.** Акчаларны кире кайтару Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының язма таләбе буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Территориаль бүлегендә ачылган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетына күчерү юлы белән бәхәссез тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**17.** Акчаларны ирекле кире кайтарудан баш тартканда алар Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтелә.

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2021 елның 19 маендагы
545-п номерлы карарына 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты резервы фондыннан бүлеп бирелгән акчаларны тоту турында хисап**

________________________________________________________________________
(резерв фонды акчаларының баш бүлүчесе (алучысы) исеме

| Күрсәтмә-нигез | Чараның атамасы | Күрсәтмә нигезендә бүлеп бирелгән акчаларның суммасы | Резерв фондыннан күчерелде | Резерв фонды акчаларыннан фактта файдалану | | | Файдаланылмаган акчаларның калган өлеше | Искәрмә<*> |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Акчалардан файдалануны раслый торган документларның исеме, датасы, номеры | Сумма | Акчаларны куллану өчен нигез (контракт, счет-фактура, КС-2, КС-3 формалары һәм башкалар). | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Җитәкче ________________ (имзаның тулысынча язылышы)

Баш хисапчы ________________ (имзаның тулысынча язылышы)

<*> Искәрмәдә акча калуның сәбәбе, файдаланылмаган акчаларны кире кайтару датасы, түләү документының номеры күрсәтелә.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 19 маендагы
545-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты резервы фондыннан акчалар бүлеп бирү турында мөрәҗәгатьләрне карау комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Баһманов М.М. | Икътисад буенча Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы, комиссия рәисе; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гатауллин И.К. | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының бюджет бүлеге баш белгече (килешү буенча); |
| Сөнгәтов Ш.Ә. | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча); |
| Хуҗина Г.Х. | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе (килешү буенча). |